| СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

8 июнь 2026 ел № 22

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Тойгужа авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 июнендәге
83 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгужа авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгужа авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгужа авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында " 2023 елның 20 июнендәге 83 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 13 нче кушымтасында 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: “Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен” Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге медален алган өчен ай саен вазыйфаи окладның 5 проценты күләмендә өстәмә түләү билгеләргә.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар үз көчен 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

Тойгужа авыл җирлеге Советы рәисе Р.А. Сафин